**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«26» сентябрь 2022 ел №404

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Ильбухтино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 26 октябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Ильбухтино авылында Верхняя урамы буенча 28А йорт янында Ильбухтино авылының Үзәк ур., Уфимская ур., Свободы ур., Нижняя ур., Верхняя ур., переулок Свободы, переулок Верхний, Второй переулок Новый, 3 йорт, буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 26 октябренә 19.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Ильбухтино авылында Мензелинская урамы буенча 36 йорт янында Ильбухтино авылының Первый переулок Новый ур., Второй переулок Новый ур., переулок Новый, Н.Вичина ур., Е.Маленкова ур., В.Лапочкина ур., Мензелинская ур., Столбовая ур., буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Ильбухтино авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

««2023 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Ильбухтино авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 1500 (бер мең бишйөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Ильбухтино авылында юлларны ремонтлау;

2) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;

3) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.Г. Даутов